**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Әтәс авылы җирлеге Иске Бикчәнтәй авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

от 25 ноябрь 2025 г. № 2

“Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принципалары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Әтәс авылы җирлеге Иске Бикчәнтәй авылында 25 ноябрь 2025 елда узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Әтәс авыл җирлеге Иске Бикчәнтәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар, көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 500 сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау
-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (зиратны төзекләндерү, Иске Бикчәнтәй авылы коймасы өчен төзелеш материаллары алу)

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 76 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40 граждан кертелде.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» позициясе өчен 40 граждан тавыш бирде;
"каршы" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.
"тоткарланучылар" позициясе өчен 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Әтәс авылы җирлеге Иске Бикчәнтәй авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: “Сез 2026 елда бер тапкыр түләнә торган, Әтәс авыл җирлеге Иске Бикчәнтәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча

теркәлгән һәм сайлау хокукына ия һәр балигъ булган кешедән хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 группа инвалидлар, студентлар , көндезге формада укучылардан тыш, җирлектәге түбәндәге эшләрне башкаруга 500 сум үзара салым кертү белән килешәсезме?:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын төзү, ремонтлау

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; кабул ителгән дип танырга.

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр төзү, төзекләндерү (зиратны төзекләндерү, Иске Бикчәнтәй авылы коймасы өчен төзелеш материаллары алу)

3. Әтәс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында әлеге карарны игълан итәргә, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга - http://aktanysh.tatar.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Актаныш муниципаль районы
Әтәс авыл җирлеге Башлыгы: Э.Ф.Насирова